| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ |
| СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 ел, №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.09.2021 ел, №20 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 5.11.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 5.12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәнең 5.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча урнаштырырга.

Сатыш авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин